*Рукопись неизвестного среди бумаг Габдулхака Хуснутдинова.*

Ислам диненең бу тирәдә кайчан кергәне билгеле түгел.

Мәккә түрәләреннән Габдулла һәм Вахит хәзрәтләр килгән.

Вахит хәзрәт Кукмара ягына җибәрелгән, ә Габдулла хәзрәт Сәйтәктә калган.

Ул “Татар көчәнде” авылы һәм Сәйтәк авылы татарларына ислам динен өйрәткән.

(“Татар көчәнде” авылы хәзерге йорт урыны дигән җирдә була, тукмаклы белән көчәнде чокыры арасында). Зиратлары хәзерге көндә дә исән.

“Мари көчәнде” авылы хәзерге тиҗек басуында бернинди динсез калалар. Аларга дин өйрәтелми.

Бу чорда бер авыл халкы икенче авылларны талап яши торган булалар, басмачылар сымак.

Кәнди дигән кеше җитәкчелек иткән (төп Тат.Сарсаз кешесе булган). Халык (басмачыларга каршы көрәшүчеләр) Кәндине чабып үтерәләр. Аның кабере тукмаклыда Псәйгә барганда тау кырыенда уң якта кала.